БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«23» 03 2026 ел

**КАРАР**
№ 139

**Балтач муниципаль районы составына кергән авыл җирлекләре территориясендә яшәүче гражданнар өчен гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Торак урынның бер квадрат метрының уртача базар бәясен куллану турында» 2026 елның 2 мартындагы 124 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2026 елда салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмен билгеләргә.

1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 655 308 сум;
1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 310 616 сум;
1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 1 965 924 сум;
1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 2 621 232 сум;
1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 3 276 540 сум;
1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 3 931 848 сум;
1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 4 587 156 сум;
1.8. Сигез кешелек гаилә өчен - 5 242 464 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең максималь кыйммәте 24 298,76 сум тәшкил итә.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2027 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен кабул иткәнгә кадәр, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аз керемле дип тану буенча җаваплы вазыйфаи

затларга (хезмәткәрләргә), гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының әлеге карар белән билгеләнгән максималь күләмен кулланырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында» 2025 елның 27 мартындагы 121 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов